МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ЗЕМЕЛЬНО-ИМУЩЕСТВЕННАЯ ПАЛАТА ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҖИР-МИЛЕК ПАЛАТАСЫ МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

18.05.2020 Алабуга ш. № 02-288

Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә

1. Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча исәпкә алу һәм мөлкәт идарәсе бүлегенә һәм җир мөнәсәбәтләре бүлегенә:

   а) Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча мөрәҗәгать иткән көннән 7 эш көне эчендә арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, 2020 елның апрель – июнь айлары өчен мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору турында өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге тәэмин итәргә, ләкин 2021 елның гыйнварыннан да соңга калмыйча;

   б) әлеге күрсәтмә үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә, Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында арендаторлар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итәргә.

   2. Аренда түләүләрен кичектереп тору арендаторларга — кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелә, алар Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш

хәлләр режимы кертелгән көнгә кадәр, Алабуга муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау килешүләре буенча алдагы чор өчен аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган арендачыларга карата гамәлгә ашырыла дип, билгеләргә;

әлеге күрсәтмәнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә төзеләчәк торган өстәмә килешүләр 2020 елның апрель — июнь айлары өчен аренда түләвен кичектереп торуны һәм аны тигез өлешләрдә 2020 һәм (яки) 2021 елларда аренда килешүендә каралган срокларда, шулай ук аренда түләүләре суммасын бер тапкыр түләүне күздә тотарга тиеш дип, билгеләргә.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.С. Гыйззәтуллин